КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 март г.Казань № 349

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гадәттән тыш хәлләр аркасында документлар югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе составын һәм Гадәттән тыш хәлләр аркасында документлар югалтканда эш стажын билгеләү тәртибен раслау турында» 1994 ел, 6 сентябрь, 438 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гадәттән тыш хәлләр аркасында документлар югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе составын һәм Гадәттән тыш хәлләр аркасында документлар югалтканда эш стажын билгеләү тәртибен раслау турында» 1994 ел, 6 сентябрь, 438 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 сентябрь, 470 нче; 2008 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы; 2009 ел, 24 декабрь, 871 нче; 2010 ел, 14 декабрь, 1068 нче; 2012 ел, 9 июнь, 499 нчы; 2013 ел, 1 август, 543 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 935 нче; 2015 ел, 21 май, 360 нчы; 2018 ел, 26 апрель, 297 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1054 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе составын һәм Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт

кенәгәләрен алып бару һәм саклау формасын, тәртибен раслау турында» 2021 елның 19 маендагы 320н номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе составын;

Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәне.»;

әлеге карар белән расланган Гадәттән тыш хәлләр аркасында документлар югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе составында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе составы»;

Асия Зиннәт кызы Вәлиуллинаның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары»;

әлеге карар белән расланган Гадәттән тыш хәлләр аркасында документлар югалтканда эш стажын билгеләү тәртибе үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
1994 ел, 6 сентябрь, 438 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 25 март, 349 нчы
карары редакциясендә)

# Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе турында нигезләмә

1. Бу Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт кенәгәләрен алып бару һәм саклау формаларын, тәртибен раслау турында» 2021 елның 19 маендагы 320н номерлы боерыгы нигезендә эшләнде һәм Гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда эш стажын билгеләү буенча республика комиссиясе (алга таба – Комиссия) эшен оештыру тәртибен һәм аның төп бурычларын билгели.

2. Комиссия «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда хезмәткәрләрнең эш стажын билгеләү максатларында төзелә. Комиссия составына эш бирүчеләр, һөнәр берлекләре яки вәкиллекле органнарның, шулай ук башка кызыксынучы оешмаларның вәкилләре хезмәткәрләре керә. Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Эш бирүче, үзендә булган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә бирелгән документларны теркәп, гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда хезмәткәрләрнең эш стажын билгеләү турындагы гаризаны (алга таба – гариза) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) кәгазь чыганакта үзе яисә почта элемтәсе (курьер хезмәте) аша тапшыра.

Министрлык гариза кергән көнне аны терки һәм, ул теркәлгән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссия рәисенә тапшыра.

4. Комиссия, гариза кергән көннән 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, аны карап тикшерә.

5. Әлеге эш бирүчедә эшләү факты, һөнәр (вазыйфа) һәм эш чорлары турындагы белешмәне билгеләү Комиссия тарафыннан хезмәткәрдә булган документлар (эш бирүче тарафыннан хезмәткәргә бирелә торган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының мәгълүмат ресурсларыннан бирелә торган хезмәт эшчәнлеге турында белешмә) нигезендә, ә алар

булмаган очракта – хезмәткәр белән бер эш бирүчедә яки бер системада эшләгән, аны шуннан белгән ике һәм аннан күбрәк шаһит күрсәтмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр хезмәткәр әлеге эш бирүчегә эшкә урнашканга кадәр эшләгән булса, Комиссия бу фактны раслый торган документларны алу буенча чаралар күрә.

6. Комиссия утырышы, әгәр анда аның кимендә өчтән ике әгъзасы (алты кеше) катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия карары, Комиссия утырышы уздырылган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Комиссия рәисе тарафыннан кул куела торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Әгәр Комиссия рәисе Комиссия утырышында катнашмаган очракта, беркетмәгә Комиссия утырышында рәислек итүче зат тарафыннан кул куела.

7. Комиссия тарафыннан Комиссия утырышы үткәрелгән көннән 10 эш көне чыкканга кадәр Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә гадәттән тыш хәлләр аркасында эш бирүче хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен массакүләм югалтканда хезмәткәрнең эш стажын билгеләү турында акт өч нөсхәдә төзелә, анда хезмәткәрнең эш чоры, һөнәре (вазыйфасы) һәм эш стажының дәвамлылыгы күрсәтелә. Әлеге акт Комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары, Комиссия рәисе йә Комиссия утырышында рәислек иткән зат тарафыннан имзалана һәм аны төзегән көннән биш эш көне чыкканга кадәр хезмәткәргә почта элемтәсе оешмалары аша җибәрелә.